КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 4 май г.Казань № 362

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында физик культура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү өчен спорт объектларын бирү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 28 февраль, 142 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында физик культура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү өчен спорт объектларын бирү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында физик культура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү өчен спорт объектларын бирү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 28 февраль, 142 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 5 июнь, 468 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында физик

культура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү өчен спорт объектларын биру белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр биру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Субсидия тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 159 нчы карары белән расланган «2019 – 2022 елларга физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы чараларын тормышка ашыруга каралган бюджет ассигнованиеләре һәм тиешле финанс елына субсидияләр биру өчен бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.»;

5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«спорт кырларын сертификацияләү буенча хезмәт күрсәтүләр.»;

6 нчы пунктның бишенче абзацын татар текстында түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмау, аларга карата банкротлык процедурасы башланмау, эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмау;»;

7 нче пунктның бишенче абзацында «үзгәртеп оештыру, бетерү яки банкротлык процессында булмавын» сүзләрен «үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмавын, аларга карата банкротлык процедурасы гамәлгә кертелмәвен, эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавын» сүзләренә алыштырырга;

13 нче пунктның өченче абзацында «субсидиядән файдалану турында» сүзләрен «субсидия биру нәтиҗәләренә ирешү турында» сүзләренә алыштырырга;

15 нче пунктта:

беренче абзацта «Субсидия күләме» сүзләрен «Субсидия күләме (С)» сүзләренә алыштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$С = З_{fks} + З_{komand} + З_{nalog} + З_{arend} + З_{ss} + З_{fot} + З_{kvalif} + З_{kommun} + З_{imuch} + З_{strah} + З_{med} +$
$+ З_{pteh} + З_{gsm} + З_{ub} + З_{ohr} + З_{bezop} + З_{sv} + З_{energo} + З_{oborud} + З_{krem} + З_{blag} + З_{obsl} + З_{eko} + З_{pit} +$
$+ З_{hoz} + З_{kanz} + З_{trans} + З_{sertif,}$»;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«$З_{sertif}$ – спорт кырларын сертификацияләү буенча хезмәт күрсәтүләр.»;

18 нче пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Юридик затлар субсидия бирелгән елдан соң килүче елның 1 февраленә кадәр бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча субсидия бирүнең килешү белән билгеләнгән нәтиҗәләренә ирешү турындагы хисапны Министрлыкка кертә.»;

икенче абзацта «нәтиҗәлелек күрсәткечләре» сүзләрен «субсидия бирү нәтиҗәләре» сүзләренә алыштырырга;

19 нчы пунктның алтынчы абзацында «нәтиҗәлелек күрсәткечләренә» сүзләрен «субсидия бирү нәтиҗәләренә» сүзләренә алыштырырга;

бу Тәртипкә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасында физик культура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү өчен спорт объектларын бирү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә
кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 4 май, 362 нче
карары редакциясендә)

Форма

20_____ елның «___» ___________ хәленә карата
субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында
ХИСАП

Юридик затның исеме: _______________________

Дәвамлылыгы: _____________________________

| Т/с | Нәтиҗә исеме | Проект (чара) исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәгә ирешү өчен кирәкле күрсәткечнең план буенча мәгънәсе | Хисап датасы хәленә карата нәтиҗәгә ирешү өчен кирәкле күрсәткечнең ирешелгән мәгънәсе | Күрсәткечнең план буенча мәгънәсен үтәү проценты | Күрсәткечнең план буенча мәгънәсеннән тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | исеме | коды | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

Юридик затның җитәкчесе
(вәкаләтле зат) ________________ ________________ ____________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

Үтәүче ____________ ___________________________ ___________________
(вазыйфасы) (Ф.Ис.Ат.ис.*) (телефон)

20__ ел, «__» ________

______________________________

* Атасының исеме булганда күрсәтелә.